РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

07.05.2026 №176/Бк/к

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 1 апрелендәге 78/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар чыгарды:

1.Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 1 апрелендәге 78/Бк/к номерлы карарына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.8.2 пунктның 8 пунктчасын «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып баруы» сүзләре белән алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов